| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** | с. Тюлячи | **БОЕРЫК**

«29» июль 2024ел | № 142

Авыл җирлекләре, предприятие,оешма, учреждение, хосусый йорт биләмәләре, күпфатирлы йортлар территорияләрен төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча смотр-конкурс турында

АҖ «ТАТМЕДИА» филиалы «Teләчеинформ» МҮ 2024 елның 10 июлендәге 18 номерлы хатын карап,

1. Авыл җирлекләре, предприятие,оешма, учреждение, хосусый йорт биләмәләре, күпфатирлы йортлар территорияләрен төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча смотр-конкурс турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Авыл җирлекләре, предприятие,оешма, учреждение, хосусый йорт биләмәләре, күпфатирлы йортлар территорияләрен төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча смотр-конкурс үткәрү комиссиясен төзергә һәм аның составын түбәндәге тәртиптә расларга:

| | | |
|---|---|---|
| Хәмидуллин И.Х. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе; |
| Гыйниятуллин Д.С. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары; |
| Хуҗин Л.Й. | - | «Теләчеинформ» МҮ җитәкчесе (килешү буенча); |
| Билалов Р.М. | - | ТР ЭТРМ ТТИ өченче разряд өлкән белгече (килешү буенча); |
| Сафина Т.Г. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты административ комиссиясенең баш белгече; |
| Котдусова Э.М. | - | «Теләчеинформ» МҮ корреспонденты (килешү буенча). |

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«29» 07 2024 № 142
боерыгы белән расланган

**Предприятие,оешма, учреждение, хосусый йорт биләмәләре, күпфатирлы йортлар территорияләрен төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча смотр-конкурс турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Авыл җирлекләре, предприятие,оешма, учреждение, хосусый йорт биләмәләре, күпфатирлы йортлар территорияләрен төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча смотр-конкурс (алга таба - Смотр-конкурс) район халкының инициативаларын үстерү, халыкны, төрле милек рәвешләрендәге оешмалар коллективларын территорияләрне төзекләндерү эшләренә җәлеп итү, иң яхшы авыл җирлекләрен, предприятиеләрен һәм оешмаларын, күпфатирлы йорт яны территорияләрен, беркетелгән территорияләрне карап тоту буенча хосусый йорт биләмәләрен ачыклау максатыннан үткәрелә.

1.2. Смотр-конкурсның бурычлары:

- төзекләндерү мәсьәләләренә халыкның игътибарын җәлеп итү;
- йорт яны кишәрлекләренә сак караш тәрбияләү, урамнарны, ишегалларын, кече архитектура формалары объектларын җиһазлау һәм карап тоту;
- торак йортларның, административ биналарның һәм җитештерү объектларының якындагы территорияләрен яшелләндерү;
- яшәү урыны буенча халык белән эшләү рәвешләрен камилләштерү.

1.3. Смотр-конкурс түбәндәге номинацияләр буенча уздырыла:

- I номинация «Иң яхшы авыл җирлеге» (1, 2, 3 урын);
- II номинация «Чәчәкле ишегалды» (1, 2, 3 урын);
- III номинация «Төзекләндерү буенча иң яхшы предприятие (учреждение, оешма)» (1, 2, 3 урын);
- IV номинация «Иң яхшы төзекләндерелгән авыл» (1, 2, 3 урын);
- V номинация «Заманча бакча» (1, 2, 3 урын).

1.4. Смотр-конкурсны оештыручылар: Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты һәм «Теләчеинформ» МУ.

1.5. Смотр-конкурс уздыруны оештыру һәм контрольдә тоту, йомгаклар ясау өчен конкурс комиссиясе төзелә.

## 2. Смотр-конкурс үткәрү һәм аңа йомгак ясау тәртибе

2.1. Смотр-конкурс ике этапта үткәрелә:

1 этап - гаризалар кабул итү - 2024 елның 10 августына кадәр;

2 этап - объектларга барып, төзекләндерүне бәяләү, йомгак ясау - 2024 елның 15 августыннан 15 сентябренә кадәр.

2.2. Катнашу өчен гаризалар ТР, Теләче районы, Теләче ав., Луговая ур., 6А йорты (“Теләчеинформ” мәгълүмат үзәге) адресы, e-mail: tulinf@rambler.ru буенча кабул ителә.

2.3. Конкурс номинацияләренең һәр критерие бал системасында тиешле баллар саны буенча бәяләнә. Һәр критерийга карата балларның иң чик әһәмияте һәр номинацияне караганда билгеләнгән. Ике һәм аннан да күбрәк катнашучының баллар тигезлеге очрагында, конкурс комиссиясе әгъзалары җиңүчене тавыш бирү юлы белән билгелиләр.

2.4. Конкурста җиңгән катнашучылар кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнә.

## 3. Конкурс критерийлары

- территорияне бизәүдә иҗади инициатива күрсәтү;
- утлар белән җиһазландырылган булу;
- территориядә ял итү урыннары (беседкалар, эскәмияләр), чүп савытлары булу;
- матур урнаштырылган клумбалар, газоннар һәм башка үсентеләр булу һәм аларның күренеше;
- халыкның территорияне җыештыру, ремонтлау, төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча күмәк эштә катнашуы.

## 4. Смотр-конкурсны оештыруны һәм уздыруны финанс белән тәэмин итү

4.1. Смотр-конкурста җиңүчеләрне бүләкләү бюджеттан тыш акчалар исәбеннән башкарыла.

4.2. Бүләкләүне гамәлгә ашыру өчен конкурс йомгаклары турында конкурс комиссиясе беркетмәсе нигез булып тора.

4.3. Һәр номинация буенча 1, 2, 3 урынны алган җиңүчеләргә кыйммәтле бүләкләр тапшырыла.

## 5. Конкурс нәтиҗәләрен ясау

5.1. Конкурска йомгак ясау турында конкурс комиссиясе карары, утырышта аның әгъзаларының кимендә өчтән икесе катнашса, дөрес дип санала.

5.2. Конкурс комиссиясе карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул гаризалар буенча территорияләрне карауда һәм комиссия утырышында катнашкан конкурс комиссиясенең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.